**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур ав. КАРАР

«14» октябрь 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Берлек – Михайловка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 27 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Вахитов ур., 2Б адресы буенча Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегендәге Берлек-Михайловка авылында Вахитов урамы, 3-24нче йортлардан, М. Җәлил урамы, 4-16нчы йортлардан, Тукай урамы 5-41А йортларында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2023 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Берлек-Михайловка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны ремонтлау (юл полотносын күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре)

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Берлек-Михайловка торак пунктының мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова